# КАРАР

**26 ноябрь, 2020 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 26 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:
- Совет, Бакча, Пионер урамнарында вак таш җәелгән юлларны төзекләндерү (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета һәм техник күзәтчелек документларын эшләү);
- Янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру (смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Су тараткыч башня өчен насос сатып алу һәм урнаштыру; смета төзү һәм техник күзәтчелек);
- Җәйге чорда территорияне чабу (бензин чапкычы сатып алу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета төзү);
- Кышкы чорда территорияне кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета төзү);
- Урам яктырткычларын алыштыру (сатып алу, урнаштыру һәм килешү буенча эшләр өчен түләү, смета төзү);
- Су белән тәэмин итү системасын төзекләндерү һәм шартнамә буенча эшләр (смета төзү, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу);
- Торак пункт территориясен төзекләндерү (өрәңгеләрне кисү, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, бензин пычкысы сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета төзү)?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 412 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 243 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 243 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «‹‹Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Совет, Бакча, Пионер урамнарында вак таш җәелгән юлларны төзекләндерү (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета һәм техник күзәтчелек документларын эшләү);
- Янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру (смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Су тараткыч башня өчен насос сатып алу һәм урнаштыру; смета төзү һәм техник күзәтчелек);
- Җәйге чорда территорияне чабу (бензин чапкычы сатып алу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета төзү);
- Кышкы чорда территорияне кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета төзү);
- Урам яктырткычларын алыштыру (сатып алу, урнаштыру һәм килешү буенча эшләр өчен түләү, смета төзү);
- Су белән тәэмин итү системасын төзекләндерү һәм шартнамә буенча эшләр (смета төзү, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу);
- Торак пункт территориясен төзекләндерү (өрәңгеләрне кисү, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, бензин пычкысы сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета төзү)?»

2. «РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Нырты авыл җирлеге башлыгы: Т. А. Котдусов

ОГРН 1021607754563
ИНН 1623001710